# ИБРАҺИМ ӘДҺӘМ ХӘЗРӘТЛӘРЕННӘН

# БИШ ТАУСИЯ



ИБРАҺИМ ӘДҺӘМ
ХӘЗРӘТЛӘРЕННӘН

# БИШ ТАУСИЯ

*

Әхмәт Томор

© Әхмәт Томор автор хокуклары - 2013

**ISBN**

978-605-88313-4-6

**Басма, китап**

“Аркам” матбагасы
Тел: 0 (212) 671 07 00

**Эзләү өчен адрес**

Тел: 0 (264) 278 9 278 - 0 (264) 274 16 31
Укырга җәлеп итү өчен оешмасы
info@okumayitesvik.com
info@tomorhoca.com

**www.tomorhoca.com**

İnternet ortamında Ahmet Tomor’un
sohbetlerine ve bütün eserlerine ulaşabilirsiniz.

**iPhone, iPod Touch, iPad**

App store > Books > Okumayi Tesvik Dernegi

**Android**

Google Play > Arama > Okumayi Tesvik Dernegi

БИШ ТАУСИЯ

# ИБРАҺИМ БИН ӘДҺӘМ ХӘЗРӘТЛӘРЕ

*

Табигыйньнәр чорының мәшһүр әүлиаларыннан берсе булган Ибраһим Әдһәм Бәлх шәһәрендә солтан иде. Ибраһим Әдһәм биш вакыт намазын калдырмаган, гөнаһлардан саклангучан, ярлыларны караган, Ислам хокукларын яклаучы һәм үз халкы тарафыннан бик хөрмәт ителүче бер хөкемдар иде. Бер кичен ясту намазын укып, ятагында йокламыйчарак ятканда кинәт сарае эчендә ниндидер тавыш купты һәм сакчылар аның каршына эре гәүдәле бер адәмне якалап китерделәр. Ибраһим Әдһәм ул буйчан кешегә ачуланыбрак:

- Син кемсең? Ни эшең бар минем торагымда, - дип сорады.

Бу дәү кеше:

- Солтаным, мин дөячемен, бер дөям югалды да, аны эзләргә чыктым, - диде.

Бу буйчан кешенең шул сүзләреннәе ачуы килгән Ибраһим Әдһәм:

- Йа, хаясыз бәндә! Син тилеме әллә? Йортта дөя эзлиләр мени? – дип кычкырды.

Мәһабәт сынлы адәм көлемсерәк:

- Син узең, бу комфорт һәм салтанатың була торып, җәннәткә кермәкчесең, нигә йортыңда дөя эзләгәнемә ачуланасың, - диде дә капылт юк булды.

Ибраһим Әдһәм бу хәлне иляһи бер хикмәт дип аңлады, бик кичеренде һәм йокламыйча төн үткәрде.

Иртәнгә кадәр бу вакыйганың тәэсиреннән арыналмаган һәм сараенда тулганып йөргән Ибраһим Әдһәм ау сылтавы белән урманга барырга карар итте һәм хезмәткәрләренә атларын хәзерләргә әмер бирде.

Атлар әзер булгач, кырык тәнсакчысы белән юлга чыккан Ибраһим Әдһәм, урманга якынлашканда сакчыларына:

- Сез мине монда көтеп торыгыз, - диде һәм гомерендә беренче тапкыр берүзе урманга кереп китте.

Әтисе Әдһәм дә солтан булганлыктан, Ибраһим Әдһәм сәрайда туып үскән иде.

Гомерендә беренче тапкыр ялгыз гизә иде. Һәм тагын берүзе, вәхши җанварлар арасында!

Урманда як-ягына каранып, уйланып торганда кош авазларына игътибар итте һәм шуларга кушылып “Аллаһ, Аллаһ!” дия-дия зекер итә башлады.

Күңеле булганчы хозурлангач, кире кайтмакчы булды, ләкин юлын тапмады, чөнки игътибарсыз килеп, эзен югалткан, кергән төшеннән ераклашкан, урманда адашкан иде. Инде чыннан да берүзе ялгыз иде һәм инде кабере урманда булачакмы? Шактый арыган, ачыккан да иде. “Бераз ашап алсам, бәлки акылым башыма килер” дип азык сумкасын тотып, атыннан төште һәм җиргә утырды. Ләкин бик сусаган

да икән әле һәм якындагы бер чокырдан чишмә тавышы да ишетелде. Егет суга барыйм дип күтәрелгән иде, көтмәгәндә бер бөркет килеп, сумкасын эләктереп, якындагы бер кыяга кунды. Ибраһим Әдһәмнең өмете төкәнердәй булды. Гүя язмыш чарыгы кирегә әйләнгәндәй иде. Инсан аягы басмаган җирдә япа-ялгыз иде, өстәвенә азык сумкасын да бөркет алып очты. Шулай итеп, тамак ялгар өчен беркет кунган кыя төбенә барып, ул кош төшергән валчыкларны җыеп ашаудан үзгә чара калмаган иде.

Бөркетне өркетеп качырмакчы булып, кыя янына килде. Ләкин алдына ачылган күренеш каршысында ушы китте, ачлыгын да, ялгызлыгын да онытты. Ни күзе белән күрсен, аяк-кулы баглаган

бер кеше җирдә чалкан ята, бөркет исә икмәген томшыгы илә ваклап йотым-йотым аның авызына каптыра.

Бөркет очып киткәч, Ибраһим Әдһәм теге кеше янына килде. Аннары бауларын чиште вә соңра кемлеген һәм аның башына төшкән маҗарасын сорады. Ул кеше әйтте:

- Мин сәүдәгәрмен. Ике көн элгәре Бугазны (Босфор бугазын) кичәргә торганда юлбасарлар кәрваныбызга һөҗүм иттеләр һәм юлдашларымны үтерделәр. Мине дә, вәхши хайваннар өзгәләп ашасыннар дип, азапланып үлергә монда китереп, бәйләп куйдылар.

- Соңрак ни булды? – диде Ибраһим Әдһәм.

- Юлбасарлар киткәчтен җаным-күңелемнән Аллага ялвардым. Чөнки мине бу хәлдән тик Ул гына коткара ала, дидем. Һәм менә, күргәнеңчә, Алла мине бу бөркетне күндерде һәм ул, оясындагы кошчыкларны ашаткан шикелле, мине ашатты.

Бу вакыйгадан соң Ибраһим Әдһәм күңлендә тәвәккәллек мәкамен уйнатып, теге кешедән хушлашып аерылды. Ибраһим Әдһәм бер капкыннан чыгып өлгермәстән, икенче капкынга кергән иде. Ярабби! Ни генә булмый бу дөньяда. Бу вакыйгаларны курчак уенында пәрдә артыннан уйнаткан шикелле барлыкка китергән зат бер Алла гына һәм чын солтан Ул гына икәнлеген аңлады Ибраһим Әдһәм. Күңлендә

тәвәккәлек көе уйналган хәлдә, ул курку, дәһшәтләрдән арынды һәм бары тик бер Аллага тапшырынды. Гүяки инде бүтән бер галәмдә яши инде һәм күңелле Алла гыйшкында яна иде. Елый-елый “Алла, Алла!” дип, зекер итеп атлады һәм үзен урман читендә ышанычлы җирдә күрде. Инде Бәлх шәһәренә кайтырга теләми иде, чөнки Аллаһу гыйшкы сәраеннан да, солтанлыгыннан да татлырак иде. Алла дуслары белән кавышып, аларның рухи фәйзиятеннән файдалану өчен горбәт юлына керде.

Алла дуслары фәйзиятеннән файдалану өчен, алар юлына керү өчен исә нәфеснең үпкә, шәһвәт, кинә, кибер, хөсет, үч, тәкәбберлек, минминлек вә дөнья сөю кебек хис-тойгыларны контроль

астына кую кирәк булгач, Ибраһим Әдһәм шулардан башлады һәм нәфесенә каршы бөек көрәш игълан итте. Сәрайда туганлыктан һәм үзе дә елларча солтанлык иткәнлегеннән ул бигрәк тә үз нәфесенең тәкәбберлек, минминлек һәм зәвәрзиннәттә яшәү кебек югары затлылык һәм шуларга баглылык хис-тойгыларнын контроль астына алу өчен нәфесенә катгый көрәш игълан итте. Нәфесенең нәселдән килгән минминлек кереннән азат булу өчен елларча җилкәсенә йөкләп утын ташыды, аны халаек күп булган урыннарда сатып, акчасын юксылларга өләште.

Бер яктан нәфес белән көрәшсә, икенче яктан рухи кимәлне саклау өчен күп гыйбадәт кылыр һәм даимән Алланы зекер итәр иде. Нәфес белән сугышу

ягъни әүлиалыкның башлангычы чыннан да бик авырдыр. Чөнки искергән, каты, иесез-төзсез һәм татсыз чи җимешләрне ашаган шикелле була. Шунлыктан әүлиалык юлына кергәнләрнең меңнән бере генә бу озын марафонны тәмамлый ала, калганнары иләнер, юлда калыр.

Иләнтекләр бу фани дөньяның алдаткыч зәвыклары беләр мавыгыр һәм күңел тарлыгыннан бер-берсе белән буышканда, марафонны тәмамлаганнар иманның вә гыйбадәтләрнең әҗерен алып, мәгънәви уңышларга, рухи хозурларга кавышыр һәм һәр ике дөньяда чиксез бәхеттә булырлар.

Һәм менә Ибраһим Әдһәм дә марафоның тәмамлап, иман-гыйбадәт

татлыгын татып мәгънәви фәйзият, рухи хозурга кавышкан, дөнья вә ахирәттә дәвамлы бәхеттә булучы, мендән бер бәндәләрнең бередер.

***

Көннәрнең берендә Әдһәм Диҗлә (Тигр) елгасының кырыенда җиргә утырып, киеменең ертылган-сүтелгән төшләрен ямый иде. Шул мәлдә яраннары берлән утеп баручы җирле вәли (губернатор) аны күреп:

- Карагыз бу бичарага, салтанатын (монда – солтан горзиен) ташлады да, кулына хәерче энәсен алды, - диде.

Ибраһим Әдһәм кулындагы энәне суга атты да, балыкларга: “Минем энәмне китермисезме?” диде. Балыкларның

барчасы су төбенә төшеп, берсе табып, авызына кабып Ибраһим Әдһәмгә китерде. Ибраһим Әдһәм энәне кулына алды, вәлигә бакты һәм: “Менә кулыма бу энәкте”, - диде[1].

***

Ибраһим Әдһәмне Алла хакына сөйгән бер кемсә бер көн аның зиарәтенә (монда – каршысына) килде һәм болай диде:

- Әй, Аллаһ дусты Ибраһим! Синең алдында мин баш иям. Чөнки син кешеләрнең күңел кереннән, пычрагыннан

---

1 Риваятьнең бер вариантында Ибраһим Әдһәм: “Хәзер син гөрзиеңне суга атып кара”, - ди. Вәли гөрзиен суга ата, хезмәткәрләр аны эзләргә суга төшеп китәләр, ләкин табалмыйлар.

дөнья салтанатын һәм дөнья зәвыкларын кулыңның аркасы илә кире эттең һәм Алла дуслары юлын сайладың. Мин сине Аллаһу өчен яратам вә синең юлыңнан китәргә телим. Әмма мин нәфсемнең гөнаһ тоткысыннан ычкыналмыйм һәм кылган тәүбәләремә дә тугры калалмыйм.

Ибраһим Әдһәм әйтте:

- Сиңа биш таусия әйтәм. Әгәр боларны җан колагын илә тыңласаң һәм тиешлесен кылсаң, нәфсеңнән, гөнаһ тозагыннан котылырсың һәм Алланың дуслары юлына керерсең.

Ул кемсә:

- Бик әйбәт, ул тәүсияләрен нидер, - диде.

Ибраһим Әдһәм әйтте ки:

1. Гөнаһ эшләрдәй булсаң, Алла яралткан ризыкны ашама! Чөнки син Алла биргән ризыкларны ашыйсың һәм шунда ук гыйсъян итәсең. Болай ярамый, бу инсанлыкка ярашмас.

2. Гөнаһ эшләр булсаң, Аллаһ биләмәләреннән кит, бүтән урын тап, чөнки Аллаһ мөлкендә утырып, аңа каршы эш кылмак ап-ачык әшәкелектер вә инсанлык чикләре тышындадыр.

3. Гөнаһ эшләгәндә Аллаһ күрмәгән бер җиргә кит һәм шунда гөнаһ эшлә. Чөнки Аллаһ хозурында гөнаһ кылмак гафләтнең аръягына киткән юньсезлектер һәм инсанлык тышында торган кыланыштыр.

4. Һич көтмәгән бер мәлдә, уйламаган җирдән каршыңа Газраил килсә, син аңа

әйтеп кара: “Әй, Газраил! Син вакытсыз килдең. Чөнки минем тагы күп эшләрем бар. Бак, кызым кияүгә чыгачак, углым солдатка китәчәк, хатыным шифаханәгә кереп дәваланачак, оныгымны сөннәтлисе бар. Яңа өем эшләнеп бетмәгән, эшем күп, түлиячәк бурычларым да бар. Шулар белән булашып, намаз укырга да, тәүбә кылырга да вакыт табалмадым. Син инде кит тә, эшләрем тәмамлангач һәм каза намазларым укылгач, килерсең.

Теге кемсә: “Мин Газраилгә «Хәзергә китеп тор, соңрак кил» дип әйтәлмим ич”, дигәч, Ибраһим Әдһәм: “Газраилгә «Хәзергә кит, соңра килерсең» диялмәгәч, нигә гөнаһ кыласың”, - диде. Әлеге кемсә елый башлады һәм: “Бәс, бишенче шартың нидер,” – диде.

5. Мәхшәр җирендә савапларың һәм гөнаһларың үлчәнгәндә савабың азрак булса, Аллаһ зобаныйларга әмер бирәчәк: **“Моны тотың, кулын муенына бағлаң, соңра җәһәннәмгә атың”** (“Хакка” сүрәсе, 30-31). Менә шунда зобаныйлар белән көрәш, кач, ничек тә җәһәннәмгә китмә!

Шулай дигәч, әлеге кемсә тагын елады һәм берни дә әйтәлмәстән Ибраһим Әдһәмгә сарылды да, ул этеп җибәргәч, китеп барды.

***

Кадерле укучыларым! Ибраһим Әдһәм кеби бер Аллаһ дустының вә заһидләр солтанының әйткән бу таусияләрен берәм-берәм карап, эчтәлекләрен ачмакчы булам, сез аларны кабул итәрәк, гамәлҗгә куегыз.

# БЕРЕНЧЕ ТАУСИЯ

*

Ике сайларлыгыбыз бар: йә гөнаһ кылып ашамый торырга, йә гөнаһ кылмаска һәм Алла яралткан ризыкны ашарга. Алладан башка һич кемсә ризык яралтмаганлыктан бер генә сайландыгыбыз, сайларлыгыбыз кала – гөнаһсыз яшәү. Бөек Аллаһу боерган ки:

**“Ризыгыгыз күктәдер һәм сезгә вәгъдә ителгән шәйләр дә күктәдер”** (“Зарийат” сүрәсе, 22).

Бер заводка энергия күндергән чем-чыбыкларда яисә энергия тудыру үзәгендә берәй ноксан булса, завод караңгыда калыр һәм җитештерү тукталыр. Дөньяга энергия күндергән табигый үткәргечләрдә

(атмосферада һ.б.) һәм табигый энергия тудыру үзәгендә (кояшта) да берәй дефект булса, дөнья караңгылыкка капланыр, җитештерү тукталыр (бер генә данә үсемлек дә үсмәс) һәм дөнья мәңгелек боз массасына әвереләр. Әйе, ризыгыбыз ягъни ризыгыбызның чыганагы күктә! Океаннарның сулары кояш нурларыннан парланып атмосферага катыла. Атмосфераның югары һәм түбән басымнары булу кояш энергиясенә баглы.

Һаваның югары басым өлкәсеннән түбән басымлы тарафка агымы (җилләр) кирәк бик тиз, кирәк әкрен булсын, ике төбәктәге басым аермасын ягъни кояш энергиясенә баглыдыр. Үсемлекләрнең һавадан амин карбонокситны (углекислый газны) оксигенга (кислородка) һәм

карбонгидратка (углеводородларга) әверелдерүе кояш нурлары тәэсирендә башкарыла. Яшеннәр яшънәве, азот газының таркалып суда эрүе һәм җирдәге элементлар белән берегешеп, үсемлекләргә азык булуы да кояш энергиясенә баглы.

Аллаһу-Тәгалә боерадыр: **“Йа, Мөхәммәт! Әйт кешеләргә: күктән вә җирдән сезгә ризык бирүче кемдер?”** (“Юнус” сүрәсе, 31). Шикләнмичә инаныгыз һәм иман китерегез ки, күктән вә җирдән ризык бирүче тик бер Алла гынадыр. Чөнки атмосфераны кояш энергиясе ярдәмендә эшли торган табигый лабораториягә әверелдерүче тик Ул гынадыр. Каты, сыек һәм газ хәлендәге атомнарны төрле химик

матдәләргә һәм ахыр чиктә ашаган ашамлыгыбызга әверелдерүче ул гынадыр. Барча мәләкләр, инсаннар вә җенләр бергәләшеп тырышсалар да бер генәкырмысканы да, бер генә үсемлекне дә барлыкка китерәлмәс!

Аллаһу-Тәгалә боерадыр: **“Аллаһы сезгә биргән ризыкны туктатса, сезгә кем ризык бирә белер?”** (“Мөлек” сүрәсе, 21).

Аллаһу-Тәгалә кояштагы гидроген (водород) атомнарының гелий атомнарына әверелеп, энергия пәйда булуны туктатса яисә кояшның тарту көчен үзгәртеп, җирне кояштан ераклатса (яки, киресенчә, бик якынлаштырса) җирдә бер үсемлек тә үсмәс, ул тәкъдирдә безгә

каян ризык килер? Кадерле укучыларым! Ашаганыбыз һәр локма өчен, эчкәнебез һәр тамчы өчен чынлап-чынлап Аллага шөкер итик. Ткмәкне кадерсезләп, түбән гөнаһ эшләмик һәм гүзәл яралтучыбызга гыйсьян кылмыйк. Шөкер итү һәм тик телдән әйтү белән генә түгел, тән хәрәкәтләребез белән дә – намаз укып Аллага тугрылыгыбызны белдерик.

# ИКЕНЧЕ ТАУСИЯ

*

Ибраһим Әдһәм әйткәнче, йә гөнаһ эшләмә, йә Алла-Тәгалә мөлкеедә утырма! Алланың игәмән булмаган бер төш тә табылмаганлыктан, безгә яшәргә бер генә юл – гөнаһсыз яшәү! Аллаһу-Тәгалә боера ки: **“Күкләрнең һәм җирләрнең бар мөлке Алланыкыдыр. Чөнки Ул үтерер, Ул тудырыр. Сезнең өчен Алладан башка нә бер дус, нә бер ярдәмче бардыр”** (“Тәүбә” сүрәсе, 116).

Күкләрнең вә җирнең мөлкияте вә игәмәнлеге документсыз-шартсыз, бәхәссез-шиксез Алланыкыдыр. Иң кечкенә барлык булган атомнардан һәм беркүзәнәклеләрдән алып гигант

йолдызларга һәм филләргә вә китларга кадәр һичбер барлык табигый яшәү кануннарыннан чыгалмас һәм үз табигатеннән аерылалмас. Югыйсә галәмдәге гомуми вәзгыять бозылачак һәм һәртөрле үлчәмнәрдә кыямәт вакыйгалары йөз бирәчәк. Аллаһу-Тәгалә дөньяны инсанның яшәү шартларына һәм инсанны дөньяның яшәү шартларына күрә яралтканлыктан, инсан дөньянгы яшәү шартларыннан чыгалмас. Һәм бүтән яшәү шартларын булдыралмас. Теләгән анында (моментында) үле туфрак матдәләренә (элементларга) хәят биреп, аларны җанлы барлыклар рәвешенә һәм янә теләгән анында (моментында) үлек итеп, янә туфрак матдәләренә әверелдерә торган Аллаһу-Тәгалә, туфрак

матдәләреннән яралткан һәр инсанны кабат асылына кайтарачак һәм шул моментта инсан җанына Аллаһтан башка ярдәмче булмаячак.

Яралтылышның вакыт-фәза законнарына каршы торалмаган, бу дөньяда яшәү мөтдәтләрен билгели алмаган, кайчан ничек үләчәген белмәгән һәм карар итеп хәл итәлмәгән, Алла билгеләгән яшәү рамкаларыннан чыгалмаган Адәм баласының тик бер генә сайларлык юлы бар, ул да булса – **гөнаһ эшләмәү!**

# ӨЧЕНЧЕ ТАУСИЯ

❋

Алланың яралткан ризыган ашап, аның җир-мөлкендә утырган хәлдә табагына төкереп, протест белдереп, аңа гыйсьян игълан итәсең икән, бүтән бер ягъни Алланыкы булмаган төбәккә кит! Шунда гөнаһ кыл.

Алланың ул күрмәгән-белмәгән бер төбәге дә юк икән – гөнаһ кылма!

Аллаһу-Тәгалә боерадыр ки: **“Нәрсәне дә булса чыгарсагыз ни дә, карангыга яшерсәгез ни – Алла барыбер барысын да белеп тора”** (“Ахзаб” сүрәсе, 54).

Гизлелек-яшертенлек бәндәләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә генә

ниндидер роль уйный. Алла катында исә яшертен ни, ап-ачык ни – аермасы юк. Аллаһу-Тәгалә халаек тыгыз утырган җирләрдә ачыктан-ачык гөнаһ кылганнарны күргән кебек, төнге карангылыкта аулак почмакта кылынган гөнаһларны да күреп тора.

Аллаһу-Тәгалә боерадыр ки: **“Нә җирдә, нә күктә хет зәррә (атом) чаклы берәй шәй дә Раббегездән гизле түгел. Һәм шуннан (атомнан) кечерәк берәй нәрсә кебек, иң зур берәй нәрсә дә китапта (ләүхел-мәхфүздә) теркәлмичә калмаган”** (“Юнус” сүрәсе, 61).

Гарәп телендә иң кечкенә берәй барлыкка ягъни атомга зәррә диелә. Аллаһу-Тәгалә, күрәсез, кешеләр

атомларны белмәгән заманда ук алар бар һәм аларның авырлыклары бар дип билгеләп үткәч, җирдә вә күктә зәррә авырлыгынча шәйләр-нәрсәләр дә Раббегездән гизле-яшерен түгел, дип боерган.

Аллаһу-Тәгалә җирдәге, диңгездәге, атмосферадагы һәм галәмләрдәге барча атомнарны белгән кебек, атомнан 100 000 тапкыр кечерәк атом тошын, ул тоштагы нейтрон-протонларны, тош тирәли әйләнгән электроннарны да күреп, билгеләп тора.

Ул, икенче яктан, бәдәнле тәнебезне оештырган күзәнәкләрне, күзәнәкләрнең чәкердәкләрен-тошларын, алардагы хромосомаларны, хромосомалардагы

геннарны вә ДНК молекулаларын күрә, белә, билгеләп тора.

Кадерлеукучыларым! Кесәтелефонын ясаучы фирмалар андый телефоннарның эчен-тышын, төрләрен-аермаларын бездән яхшырак белгән кебек, безне яралткан Алла да эчебезне-тышыбызны, күзәнәкләребезне, күзәнәкләребездәге тошларны, тошлардагы хромосомаларны, хромосомалардагы геннарны, ДНК молекулаларын, аларның барча нечкәлекләрен бездән дә яхшырак белеп тора.

Зинһар, вөжданыбызга алып, уйлап карыйк – безне үзебездән дә яхшырак белгән Алла колларының яшертенме-ачыкмы кылган гөнаһларын белми калыр

дисезме? Юк инде, бердәнбер сайлар юлыбыз – **гөнаһсызлык юлы!**

# ДҮРТЕНЧЕ ТАУСИЯ

❋

Һич көтмәгәндә, уйламаган җирдән каршыбызга Газраил килеп басканда без үлергә әзер түгеллебезне һәм үлергә теләмәгәнлегебезне беләбез. “Зинһар, хәзергә китеп тор, соңрак килерсең!”

Әмма, үткәннәрдәге тасвирламаларга карасак, пәйгамбәрләрне дә исәпкә-санга кертеп. Һичкемсә Газраилгә “хәзергә кит, соңрак килерсең” диялмәгән кебек, без дә диялмибез, бәс, үлемне кабул итәргә, каршылыларга һәрвакыт әзер булырга тиешбез.

Чөнки Аллаһу-Тәгалә боера ки: **“Һәр тыналучы үлемне татыячак һәм соңра безгә кайтачаксыз”** (“Ганкабүт” сүрәсе, 57).

Инсанны хайваннан аерган иң мөһим фактор физик-бәдәни төзелеш түгел, һуш-акылдыр. Акылның бурыч эше – киләчәкне күреп, кирәклекне аңга алмактыр. Үлем барча кешеләрнең уртак язмышы булганлыктан, үлемне оныту, хәтердән жую, хәтәр килгәндә башын комга тыккан дәвәкош кебек кыланудыр. Күзләрен киләчәктән каплап, дәвәкошлар кебек тормыш былчырагына башы белән чумганнарга берни аңлаталмасагыз, үзегезгә үлем хакыйкатен күреп, шуңа хәзерләнергә кирәк.

Аллаһу-Тәгалә боера ки: **“Кайда гына булсагыз да, үлем сезне табар, ныклыдан ныклы, биектән биек кальгаләр корсагыз да, үлем ишекләрегезне ача белер** (“Ниса” сүрәсе, 78).

Тудырылып, дөньяга килү сезнең теләгегезгә карамаган шикелле, үлеп, ахирәткә китү дә сезнең ихтыярыгызда түгел. Аулак чүлләргә качсак та, ныклы кальгаләргә сыгынсак та, караңгы мәгарәләргә яшеренсәк тә, заманча коралланган гаскәри частьләр тарафыннан саклансак та яисә дөньяның иң модерн хастаханәләрендә иң атаклы һөнәрмән врачлар күзәтүендә яшәсәк тә, күверелгән чаралар безне коткармас, Газраилгә үз бурычын үтәргә комачауламас.

Үлем соң нәрсәдер ул? Җан һәм тән берлегенең бозылуыдыр. Матдилектән тыш фәрештәләр шикелле яши алган рух-җан тәннең мәгънәви электригы кебектер. Заводның электр үткәргечләре киселсә, барча машиналар тукталган шикелле,

тәннең җан белән бәйланышлары өзелсә, барча яшәү функцияләре тукталыр һәм тән-бәдән җансыз бер ит кисәгенә әверелә. Рух-җан инсанның сылы, үзе[2], өзелмәс-киселмәс дәвамчан берәмлеге, тән исә аның бу дөньядагы вакытлы күренешедер.

“Ит-сөяккә керендем, Юнус булып күрендем”, -

Дигән беренче бөек төрек шагыйре Юныс Әмрә. Үлемне үч алыну һәм кабер караңгылыгы, ямьсез чокыр дип күзәфәләмик. Чөнки үлем ул юк булу түгел. Бүтән бер хаятькә күчү генә. Үлем – рухның бәдән зинданыннан котылып

2 Сыл, үз – җанлы массада эчке хәрәкәт-үзгәрешләрнең сәбәпчеләре

җила (бәрзах)[3] мәйданында үз-үзлегеңне кабат танудан гыйбарәт.

Әмма бер кирчәкне дә онытмыйк: фани дөньяда өебезне иминчелек кассасында гәрәүләтеп куйган шикелле каберебезгә дә рухи капитал салып куйыйк. Дөньялыкта өебезне люкс әйберләр илә бизәгән һәм бәллур люстралар илә яктыртканыбыз шикелле каберебезне дә намаз, ураза, зәкят, Коръән, зекер һәм салавати-шәрифә кебек мәгънәви әшьялар илә бизик, иман илә яктыртыйк. Бигрәк тә дөньяви өебезне зарарлы вә зәһәрле бөҗәкләрдән арындырган шикелле мәзарыбызны[4]

3 Җила яки бәрзаһ – кешеләрнең җаннары гомуми кыяматкә кадәр тора торган урын.

4 Мәзар – күмелгән яки һәләк булган урының (киң мәгънәдә). Бәрзаһтагы урының.

да зарарлы вә зәһерле рухи еланнардан коткарыйк.Чөнки гөнаһларыбызның һәрбере анда безнең белән бергә елан булып ятачак һәм кыяматкә кадәр азаплаячак.

Бәрзаһ (җила) галәмендә рухыбызны тыныч итик һәм мәзарыбыз ук җәннәт бакчасындай булсын дисәк, гөнаһлардан качыйк вә гыйбадәтләребезне төзген рәвештә башкарыйк. Дөньялыкта тәүбә иткән һәм гөнаһлардан арынган мөэминнәр мәзарда тоткын булмас. Теләгәннәре Мәккәгә китеп Кәгъбә турысында очып йөрерләр, Мәдинәдә пәйгамбәр каберен зиярәт итәрләр, күк йөзен гизәрләр. Бигрәк тә бүтән пәйгамбәрләр, әүлиалар үзләреннән элек үлгән дуслары, кардәшләре белән

сөйләшерләр. Аллаһы дусларыннан берсе зиратта йөргәндә елый башлаган. Нигәлеген сораганларга: “Аһ, җир астында җәннәт тә бар, җәһәннәм дә бар”, - дигән.Кадерле кардәшләрем! Үлем фәрештәсе безне күзәткән шикелле җәннәт вә җәһәннәм дә безне көтеп торалар. Газраил көтмәгәндә каршыбызга килеп басканчы, **“Хәзергә кит, соңрак килерсең”**, - дип әйтеп булмагачтын, алданук тәүбш итеп, гөнаһлардан арыныйк һәм үлемтек токчаебызны гүзәл рухи хәзинәләр белән тутырыйк.

# БИШЕНЧЕ ТАУСИЯ

*

Мәхшәр җирендәге мәгънәви үлчәүдә савабың аз һәм гөнаһың күп булып чыкса, Аллаһу-тәгалә сине дәһшәтле зобаныйлар карамагына тапшырачак. Әгәр зобаныйларга каршы торырлык көчең булса, әйдә, гөнаһ кыла бар. Югыйсә хәзер үк тәүбә ит һәм гөнаһ эшләрне кире как!

Аллаһу-тәгалә боерадыр ки: **“Сур беренче тапкыр өрелгәч үк, Аллаһ үзе генә коткармаса, күкләрдәге вә җирдәге барча барлыклар куркудан егылып үләчәк”** (“Зүмәр” сурәсе, 68).

Хәзрәти Исрафил Алланың әмере илә Сурга беренче тапкыр өргәч Кыямәт

кубачак, барча җан ияләре куркудан акылдан язып үләчәк һәм җирләр вә күкләрнең асты өсткә килеп, яңа тәртиптә яңадан корылачак.

Аллаһу-тәгалә боерадыр ки: **“Сур кабат (икенче тапкыр) өрелгәндә инде каберләреннән чыгып утырган бәндәләр туп-туры мәхшәр җиренә китерелерләр”** (“Ясин” сүрәсе, 51).

Инсаннарның кабер яныннан очып килеп дөньядагы кылмышлары өчен хисап бирергә мәхшәр җиренә китерелүе аларның гомерендә иң әһәмиятле көн булачак. Чөнки нәкъ шунда алар йә оҗмахлы, йә тамуглы булачак.

Аллаһу-тәгалә боерыр ки: **“Ул көнең залим пошайманлыктан тырнана-**

**тырнана «аһ, кяшка пәйгамбәр белән бергә бер юлдан йөрсә идем», - диячәк”** (“Фуркан” сүрәсе, 27).

Дингә каршы көрәшкән акылсыз идеологлар һәм акылсыз системаларга ылыгып мөселманннарны бастырыклаган залимнәр:

- Аһ, кяшки мин дә пәйгамбәр белән бергә, бер юлдан брган булсам иде, - дип кулларын шатырдатып кимерәчәк. Табигый ки, эш узган була!

Табигый ки, эш узган була!

Мәхшәр җирендә әүвәл гамәл дәфтәрләре таратылачак һәм шуннан соң Мизан корылып, һәркемнең гөнаһы вә сәвабы һлчәнә башлыячак.

Аллаһу-тәгалә боера ки: **“Без кыямәт көненә гадәләт үлчәүләре таразиләр корачакбыз. Анда һичкемсәгә һичтөрле хаксызлык кылынмас. Эшләнгән савап яки гөнаһ хардал[5] орлыгы кадәр генә булса да, без аны үлчәүгә куячакбыз”** (“Әнбия” сүрәсе, 47).

Әйткәнебезчә, мәхшәр җирендә савапларны һәм гөнаһларны үлчи торган мизанлар корылачак. Шәкелен һәм ниндилеген без белмәгән ул мизаннарның уң табагына саваплар һәм сул табагына гөнаһлар куелачак. Иляһи гадәләт күрсәткече булган ул мизаннар бик сизгер булачак. Тик бер хардал данәсе авырлыгындагы савап яки гөнаһларны да

5 Хардал (хәрдәл) безнең икълимдә булмагач, аның урынына татарлар тары бөртеге, мәк орлыгы дип тә язалар.

төгәл үлчәгән кебек, бөтен җир шарыннан зуррак һәм авыррак савап вә гөнаһларны да шул ук төгәллек илә үлчиәчәк. Мизаннар корылып, үлчәүләр башлангач, киеренкелек соң дәрәҗәгә җитәчәк: кешеләр куркудан дер-дер тетрәп, күзләрен мизаннан аермаячак. Чөнки бәндәнең язмышы шунда билгеле булачак. Мизанның сул табагына кап-кара һәм чиркен бер кыяфәттәге гөнаһлар куелгач, гөнаһкярлар үз гөнаһларыннан куркарак, гарьләнүдән чәчләрен йолкачак, мизанның уң табагына нурлы, ап-ак шәкелдәге саваплар куелгач, моны күргән мөэминнәр сөенечтән, “аһ, кяшка тагын күбрәк саваплыклар эшләгән булсамчы!”, - дип үзләрен чәбәкләячәк.

Мизанда үлчәү намаздан башланачак. Укылган намазларның да, кылынмаганнарның да үлчәмнәре бик

зур һәм савап-гөнаһ чагыштырмасында-кыясында намазның әһәмияте хәлиткеч әһәмияткә ия булачак. Соңыннан ураза, зәкят һәм хаҗ кебек исламның нигезен тәшкил иткән гамәлләргә чират киләчәк һәм бу гыйбадәтләрнең үлчәмнәре дә, бик зур булып, мизанның уң табагына куначак. Табигый ки, киресенчә – укылмаган намазлар, тотылмаган уразалар, бирелмәгән зәкятлар һ.б. мизанның сул табагына куелачак.

Исламның нигез ташларыннан булган нәфилә (фарыздан тыш) гыйбадәтләр чираты киләчәк һәм кирәк сүзле, кирәк акчалата, кирәк әйберләтә кылынсын, бу савапларның һәрберсенә аерым савытлар биреләчәк һәм алар берәм-берәм мизанның саваплар табагына

куелачак. Илаһи гаделлек берәмлекләре булган һәртөрле хәерләр һәм игелекләр дә, хардал данәсе кадәр булса да, бәяләнмичә калмаячак һәм боларның һәрберсе мизанның уң табагына куелачак. Күңеленнән бер мәртәбә "Алла!" дигән бер тапкыр "Бисмилла" дип әйткән, берәүгә мөселманча сәләм биргән, бер хастаны барып күргән һәм хәлен сораган, бер мескеннең яки гозерленең теләген үтәгән яки кулыннан тотып күңелен күтәргән бер юксылга аз гына булса да ярдәм иткән инсан, бу игелекләрне кайчан эшләнлеген үзә дә оныткан булса, савабын күргәч, елап җибәрәчәк.

Ә гөнаһлар? Әлбәттә, алар да берәм-берәм мизанга куелачак һәм, мәк орлыгы кадәр булса да, җәзасыз калмаячак. Бер

йотым булса да аракы эчкәннәр, вакыт уздыру дип кенә дә комар уйнаганнар, кеше хатыны яисә ят хатын белән хет кул кысышкан ирләр, никяхсыз иргә сарылган хатыннар һәм кыска арада булса да ярым ялангач гизгән хатын-кызлар бу кылмышларның гөнаһын күргәч, бик пошайман булып, бик үкенәчәкләр.

Ә зур гөнаһлар? Аларның шәрреннән-зыяныннан дөньяда вә ахирәттә Алла үзе генә сакласын һәм барча инсаннарга тәүбә итеп, исламга кайтуларын насип итсен. Амин!

Аллаһу-тәгалә боера ки: **“Ул көн-үлчәү көне хактыр. Кемнең савaплары аскарак тартса, анлар фәлах-җәннәт белән кавышырлар”** (“Әгъраф” сүрәсе, 8).

Ягъни мизанда саваплары агыр басканнар соңсыз-ахырсыз галәме булган җәннәткә ирешәчәкләр һәм анда һәр яктан ышанычлы хәлдә дәвамлы бәхеттә вә хозурда яшәячәкләр. Җәннәткә киткән юлны мизандагы гөнаһ-савап тиңгеллеген күрсәткән ук – нәйзә күрсәткәнлектән, ул нәйзәнең торышы кешенең дөньяда ничек яшәвенә баглы булганлыктан, бердән бер сайларлыгыбыз бу фани дөньяда савапларыбызны арттырмактан һәм гөнаһларыбызны кыскартмактан гыйбарәттер.

Шуннан үзгә бүтән сайлар юлыбыз һәм өметебез-ышанычыбыз юктыр. Уртача гына шиддәтле җиртетрәүдән һушы китә торган, яшен яшьнәүдән, күк күкрәүдән йөрәге кузгала торган бәндә

Аллаһу-Тәгалә зобаныйларга **“Моны тотың, кулын муенына баглаң, соңра аны җәһәннәмгә атың”** (“Хакка” сүрә, 30-31). Дип әмер биргәчтән, барча түбән кылыклар кыла-кыла җәһәннәмгә китүдән башка ни эшләсен!

# НӘТИҖӘ

*

Кадерле укучыларым! Заһитләр солтаны Ибраһим Әдһәмнеж бу биш таусиясе яктылыгында кайбер гомумиләштерүләр ясыйк һәм үзебезнең киләчәгебезгә баглы кайбер нәтиҗәләргә дә килеп карыйк. Менә без юл чатындабыз һәм каршыбызда ике белдерү тактасы бар, ди. Берсенә “Ожмахка юл” дип, икенчесендә “Тәмугка юл” дип язылган, ди.

Җәһәннәмгә киткән юлга баксагыз моторы шартлап контрольдән чыккан бер машинадай иман моторы шартлаган һәм акылы-руле дә бозылган динсез, тәртипсез, хозурсыз, таһарәтсез һәм намазсыз тупламны күрерсез.

Алкоголь һәм наркотиклар, комар һәм фәхеш баткаклыкларында саулыкларыннан язганнар, исен, эшен, кешелекләрен югалтканнар, былчыракта яшәп акылларын җуя башламышлар капиталистик системаның кредит карточкалары буталчыгыннан котылмак өчен үз-үзен үтерүдән үзгә юл тапмаганнар... Бер-береннән аерылган парлар, туздырылган оялар, урамда калдырылган балалар... Кече яшьтән сәламәтлеккә зарарлы тиешсез җенси мөнәсәбәтләргә юлыккан, террористик группаларга һәм наркотиклы төркемнәргә тартылган караусыз мескен үсмерләр...

Отышлы уен мафияләре, җир асты даньялары, караңгы эшләр, рисвайлыклар, азгынлыклы багланышлар һәм канлы террористик кыланышлар...

Яшәешне сәләмәтләндерергә бурычлы дәүләт полициясенә ташлар, күсәкләр, молотов коктейлләре илә һөҗүм иткәнләр, караңгы көчләр тарафыннан явызларча файдаланылган, әрәм булган белемсез үсмерләр...

Икенче яктан, шундый тирәнлектән файдалану өчен яңгын утына үзләре теләп керүчеләр дә бар.

Ташландык тирәлек, кара көчләр һәм кара көчләр контролендәге гөнаһлы һәм гөнаһ карашлы тирәлек!

Дингә каршы агитация һәм махсус тантаналар, җыеннар, хыялый регрессив лозунглар һәм халыктан алынган салыннар исәбенә тантаналап әйтелгән тостлар! Ләкин боларның соңы ни булачак?

Гөнаһлардан чыгып тәүбә итәр булсалар, кояш баеп кояш чыкканга кадәр дә тәүбә капкасы һәркемгә ачыктыр. Тәүбә итеп гөнаһлардан арынганнар һәм иманның татын белеп, рухи хозурга кавышмышлар: “Аһ! Мин нигә алданрак тәүбә итмәдем икән?!”, - дип күкрәкләренә орырлар. Ә тәүбә итмичә үлгәннәре?

Алла сакласын, әмма алар юл башындагы кагыйдә буенча билгеләнгән җиргә ягъни җәһәннәмгә китәрләр

***

Җәннәткә киткән юлга багып күрсәк! Дини әмерләр күрсәтүенә тугрыкрыкры, тәртипле, хозурлы вә саулыклы яшәгән тупламнарны күрәбез. Дөнья өчен дөньяда калачаклары кадәр һәм ахирәт өчен

ахирәттә калачаклары кадәр тырышып, мәгънәсез хирыска бирелмәгән һәм гыйбадәтләрен калдырмаган ышанычлы инсаннар тупламы...

Дин кардәшлеге хиссиятендә эреп Алла өчен бер-берен ятратканнар һәм көн биш вакыт намазга җыелышып бер-берсенең хәл-әхвәлләре илә уртаклашалар...

Зәкят, фитыр, корбан, нәзер, ураза кифәрәте, ямин кифәрәте һәм төрле нәфилә садакалары белән юксылларны, ятимнәрне һәм ярдәмсезләрне күреп ярдәм иткән чын мөэминнәр...

Намаздан алган рухи көч ярдәмендә нәфесләрен контрольдә тота белгән һәм шуңа күрә алкоголь, наркотик, комар,

алдак, гайбәт һәм кул ягу (кыйнау) кебек гөнаһлардан качучан мөселманнар...

Аллаһу-тәгаләнең “Зинага салышмагыз” дигән әмерен тотарак, кулларын, телләрен, күзләрен һәм женси органнарын зинаның һәм төреннән читтә тоткан, женси теләкләрен зәвежләре белән канәгатьләндерүче һәм шундый шатлыкларны үз өйләрендә генә эзләгән чын мөэмин-мөселманнар...

Бәхетене үз ояларында эзләп, бүтәннәрнең зәвеж-зәүжәләренә күз салмаган һәм шунлыктан аерылышуны башларына китермәгән һәм бик кирәккәндә генә Аллаһү-тәгалә яратмаган аерылышу хәленә барган, әмма балаларының тәрбиячесе буларак,

аларны урамда калдырмаган инанычлы аналар һәм аталар! Инде боларның хәле ни булачак?

Үз юлларыннан тайпылмыйча үлсәләр, һич шиксез юл башында таблода язылган “Оҗмахка” дигән язуга ярашлыча, шунда китәчәкләр һәм анда даимән бәхеттә булачаклар.

# ҖӘННӘТ ҺӘМ ИНСАН

Аллаһу-тәгалә боерадыр ки: **“Раббегезнең багышламасына күрә һәм тәкъвәлекияләре (гөнаһлардан куркучылар) хәзерләнгән, күләме җирдән күккә кадәр булган җәннәткә йөгерсен!**

Бәдән һәм сизем үзенчәлекләре буенча бозлы океаннарның суык сулы яшәү шартларына күнеккән китларга безнең күлләр тар һәм бөркүле булган шикелле, бәдәни һәм рухи үзенчәлекләре җәннәт шартларына яраштырылып яралтылган инсаннар өчен бу дөнья тар һәм бөрештерүледер. Чөнки атабыз Адәм һәм анабыз Хаува мең елларча җәннәттә яшәделәр. Ашадылар, эчтеләр һәм бөтен

гүзәллеге илә җәннәт шартларында калдылар. Соңра, шайтаннан алдатылып, бу җир планетасына сөргенгә җибәрелделәр. Ул гүзәл җәннәт тормышына күнекмеш атабыз Адәм белән анабыз Хаува бу җир планетасы аларга тарлык һәм рухи рәхәтсезлек китергәч, бу дөньяны уңайлы дип тапмадылар вә җәннәтне сагынып, ахирәт галәменә күчеп киттеләр.

Зоопарк бакчаларында туган һәм урман-далаларны һич күрмәгән арыслан балаларының генетик төзелешләрендә һәм инстинктларында зур киңлекләрне сагуны булган шикелле, бу дөньяда туган һәм җәннәтне һич күрмәгән инсаннарның генетик төзелешләрендә вә инстинктив белемнәрендә дә җәннәт шартларының

үзенчәлекләре яшәгәнлектән, ахирәткә вә җәннәткә һич ышанмаганнар да аеруча гүзәллекне күрсәләр, "җәннәт" кебек диләр һәм, шулай итеп, яшертен шәкелдә җәннәтнең барлыгын таныган булырлар.

Әйе, җәннәт бардыр һәм һәр кешенең киләчәк идеалында, астаңында тумыштан җәннәт образы-кибәрәсе яши. Шул сәбәптән кешеләр һич урынсызча "җаным кысыла", "күңлем тарая" диләр икән, бу хәл җәннәтне сагынудан һәм дөньявилыктан рух канәгать булмавыннан каләдер. Чөнки рух һәрчак өметле үлемсез бер хәят эстәр. Дәвамлы хозурлык, дәвамлы бәхет, саулык һәм яшьлек теләр. Туктаусыз әйләнеп торган һәм галәмдәге торышы, әхвәле төрлечә, көтелмәгән үзгәреп торган бу дөньяда

кешеләрнең гади материаль законнар нигезендә яхшырак шартларга ирешүе мөмкин түгел.

Аз гына һәм тиз узучан кайбер бәхетле мизгелләрдән тыш бу дөньяда хозурлы булып тынычлык табалмаган, нарасыйлыгы елап, мәктәп еллары авыр сынауларда, картлыгы авыруларда кичкән, соңра улем ятагында әҗәл тирләре түккән, каберенә кыстырылган, мәхшәрдә туналган һәм сират күперендә янган **ИНСАН**.

Бары тик җәннәткә кергәч кенә җанының һәр теләгенә, тирәнтенге эстәкләренә, кирәкле һәр нәрсә әзер булгач, рухи хозурга, дәвамлы бәхеткә һәм үлемсез яшәүгә ирешәчәк.

Аллаһу-Тәгалә боерыр ки: **“Тапсыз мөттәкыйлар (гөнаһлардан һәрчак сакланганнар) күләгәләрдә, чишмәләр янында, җаннары теләгән җимешләр арасында булачак. Мәләкләр аларга әйтерләр: ‘Кылган гыйбадәтегезнең әҗере бу, рәхим итеп ашагыз, эчегез’”** (“Мөрсәләт” сүрәсе, 41-43).

Дөньяда Алладан курыкмаган һәм бүгенгелек өчен иң чиркен гөнаһларны да ачыктан-ачык кылмышлар мәхшәрдәге сораулардан соң җәһәннәмдә чытырда янар, зәккум агачының ачы һәм сассы җимешләрен ашар вә алларында быгыр-быгыр кайнаган нәҗес суларын эчәр икән.

Дөньяда Алладан куркып һәртөрле гөнаһлардан эзлекле рәвештә сакланганнар һәм биш вакыт намазны

тәртибенчә башкарганнар җәннәт агачлары күләгәсендә, яшәү чишмәләре янында һәм җаннары теләгән төрле-төрле җимешлекләр арасында туеп-туеп ашаячаклар, эчәчәкләр, сөхбәтләшеп күңел ачачаклар. Мәләкләр аларга әйтәчәк: “Дөньяда эшләгән игелекле эшләрегезнең әҗерен күрәрәк монда хозурланып ашагыз, эчегез”. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтәдер ки, җәннәттәгеләр шунда ашарлар, әчәрләр, әмма тышкы олы һәм кече хаҗәтләре булмас, какырмаслар, сеңгермәсләр. Бары тик хуш исле сулыш вә тирләре булыр (Мөслим). Җәннәттәге мөэминнәр һичбер физиологик кысталмага дучар булмыйча һәртөрле тәгамьнәрне җийгән-ашаган хәлдә туалетка мохтаҗ булмаслар һәм авыраеп симермәсләр дә.

Ана карынындагы бәбәкләрнең эчәк-бавырлык һәм сулыш системалары эшләмәгән шикелле, оҗмахтагыларның да эчәк-бавырлыклары эшләмәс, ашаган-эчкәннәре сизелдермичә газ вә тир төсендә чыгарылачак.

Җәннәттә төкермәк, сеңгермәк, кикермәк, какырык, күз яше, колак сагызы кебек шәйләр булмаган кебек, чәчләр, тырнаклар да үсмәячәк һәм җенси мөнәсәбәтләрдә дә билгеле билгеле юешлекләр булмаячак.

Җәннәтнең сәрайлары көмештән, энҗедән, алтыннан, диваннары якуттан, зөбәрҗәттән, мәрҗәннән вә ятак-ястыклары, мөэминнәрнең эчке һәм тышкы киемнәре җәннәт ефәгеннән эшләнәчәк.

Җәннәттә бер ир дә, бер хатын да ялгыз калмаячак. Дөньялыкта өйләнмәәгннәр яисә ише-кушы җәһәннәмгә эләккәннәр үзләренә яхшырак иш-куш табачаклар.

Җәннәттә ир вә хатыннарның һәртөрле теләкләре иң яхшы төстә үтәләчәк, сөешкәннәр иң бәхетле рәвештә сөешәләр. Җәннәттә һәр шәй дәвамлы һәм тоткарсыз булгачтын, бәхетләре чиксез дәвамчан булачак. Миллиардларча еллар кичсә дә сөю һәм рәхәтлектән өзелмәячәкләр. Киресенчә, сөешү һәм рәхәтлекләр артачак кына.

Җәннәттә дәүләтчелек, армия, суд һәм полиция кебек гомуми иминлекне һәм идарә авторитетын саклый торган оешмалар булмаган хәлдә дә хозурлык һәм иминлекне боза торган бер генә күренеш

вә вакыйга да йөз бирмәячәк. Һәркем үз теләгенчә беркем дә аңа комачауламаган хәлдә яшәячәк.

Җиде кат күкләрдән һәм күкләрдәге галактикалардан да бөекрәк булган җәннәт, җир шары шикелле берәй кояш тирәсендә әйләнмәстән, гареш нуры илә яктыртылганлыктан, җәннәтнең һәр тарафында дәвамлы көн, дәвамлы язгыча һавалы икълим булачак.

Кече яштүк үлгән балалардан тыш, барча хатын вә ир-егетләр җәннәттә утыз өч яшь кимәлендә (ягъни һушы-акылы да, организмы да иң җитлеккән хәлдә) яшәрләр. Бу хәлләреннән рухи хәләте дә, физик көчләре дә, кыяфәтләредә үзгәрмәячәк.

Җәннәт күз күрмәгән, колак ишетмәгән һәм инсаннарның күңеленә вә хыялына да килмәгән гүзәллекләр һәм сыйфатлар галәмедер. Рухлар галәменнән ана рәхменә һәм аннан дөньяга килгән инсанның соңгы торагы җәннәт яисә – Алла сакласын – җәһәннәмдер.

***

Кадерле укучыларым! Идарә кулыбызда, карар үзебездә һәм Газраил артыбызда торганлыктан, тизрәк күңел карарына килик һәм юл чатында чайкалып тормыйк. Юл чатындагы күрсәткечләрне күрми калып, җәһәннәм юлына киткән булсак, дәрхаль кире борылыйк һәм асыл табигатебезгә буйсынып, җәннәт юлына керик.

Югыйсә үлем фәрештәсе Газраил каршыбызга килеп басканда инде соң булмагае, ул “соң калдың” димәгәе һәм җаныбызны газап фәрештәләре кулына тапшырмагае.

Бездән сүз, Алладан ярдәм һәм кулдан-күңелдән гайрәт!



# Cennet,

gözlerin görmediği,
kulakların duymadığı ve
insanların kalbine, hayaline
gelmeyen güzellikler ve
farklılıklar âlemidir.

Ruh'lar âleminden
ana rahmine ve oradan da
dünyaya gelen insanın
son durağı cennet ya da
cehennemdir.

Okumayı Teşvik Derneği

Эзләү өчен адрес
info@okumayitesvik.com
Тел: 0 (264) 278 9 278 - 274 16 31

*Hediyedir...*

**Para ile Satılamaz**

ISBN 978-605-88313-4-6
9 786058 831346